РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.06.2019 Акбаш тимер юл станциясе посёлогы № 26

2019 – 2029 елларда
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
Акбаш авыл җирлегендә
транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү
программасын раслау турында

2016 елның 27 июлендә Россия Федерациясе транспорт министры М.Ю. Соколовның транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә номатив-хокукый актларны гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе субъектлары җитәкчеләре белән уздырган селектор киңәшмәсенең муниципаль берәмлекләр өчен транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программасын эшләү һәм раслау өлешенә кагылышлы 58нче беркетмәнең 2нче өлешенең 2нче пунктына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 19 декабрендәге №03-16/5899нчы хатына туры китереп, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә, куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү белән беррәттән, транспорт инфраструктурасы үсешен тәэмин итү максатында,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 – 2029 елларда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программасын расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Акбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Т.Хуҗиев

Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты карары
белән расланган
2019 елның “24” июне №26

# 2019 – 2029 елларда
# Татарстан Республикасы
# Бөгелмә муниципаль районы
# Акбаш авыл җирлегендә
# транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү
# ПРОГРАММАСЫ

Акбаш тимер юл станциясе посёлогы
2019 ел

# 1. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Программа атамасы | 2019-2029 елларда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| 2. | Программаның заказчысы, эшләүчесе һәм үтәүчесе | Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3. | Программаны эшләү өчен нигез | - 2014 елның 29 декабрендә кабул ителгән “Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше турындагы кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы № 456-ФЗ Федераль законы;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.12.2015 елның 25 декабренда кабул иткән “Җирлекләр, шәһәр округларында транспорт инфраструктурасы системасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында”гы №1440 карары;<br>- Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 6 июнендә биргән «Муниципаль берәмлекләрдә транспорт инфраструктурасы системасын комплекслы үстерү программасын эшләү турында”гы №326661 - МР биреме. |
| 4. | Программаның максаты һәм бурычлары | Максат: «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлегендә, куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү белән беррәттән, транспорт инфраструктурасы үсешен тәэмин итү».<br>Бурычлар:<br>Транспорт инфраструктурасы объектлары төзелешен, реконструкцияләүне тәэмин итү;<br>Муниципаль берәмлек территориясендә юл хәрәкәте куркынычсызлыгын күтәрү |
| 5. | Транспорт инфраструктурасы үсешенең максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) | Җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланыштагы автомобиль юлларының озынлыгы;<br>Транспорт инфраструктурасы объектлары |

| | | |
|---|---|---|
| | | төзү, реконструкцияләү проектларының саны;<br>Төзелгән, реконструкцияләнгән автомобиль юлларының озынлыгы;<br>Юл хәрәкәтен оештырганда кертелгән техник чараларның саны. |
| 6. | Гамәлгә ашыру сроклары | 2019-2029 еллар |
| 7. | Программа чаралары | 5нче “Транспорт комплексы үсешенең приоритетлары” бүлегендә китерелгән |
| 8. | Финанслау чыганаклары | ТР бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар |
| 9. | Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | Муниципаль берәмлек территориясендә транспорт инфраструктурасын үстерү өчен шартлар булдыру;<br>Муниципаль берәмлек территориясендә юл хәрәкәтендә катнашучыларның сакланганлык дәрәҗәсен күтәрү. |

## 2. Гомуми мәгълүматлар

“Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасының көньяк-көнбатышында Бөгелмә муниципаль районында урнашкан, административ үзәге - Акбаш тимер юл станциясе посёлогы, Вязовка, Петровка, Зеленая Роща авыл җирлекләре, “Бөгелмә шәһәре” муниципаль берәмлеге, Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш.

Авыл җирлеге составына өч торак пункт керә: Акбаш тимер юл станциясе посёлогы, Андреевка һәм Кирилловка авыллары. Авыл халкы сан ягыннан 01.01.2019 елга 675 кешене тәшкил итә. Җирлек территориясе – 8430 га.

Җирлекнең административ үзәгеннән Бөгелмә муниципаль районы административ үзәгенә – Бөгелмә шәһәренә кадәр ара 20 километрга якын.

## 3. Транспорт инфраструктурасы сыйфатламасы

Җирлек территориясендә тышкы транспорт ике төр – автомобиль һәм тимер юл төре белән бирелгән. Җирлекнең торак пунктларында тышкы транспортның күләме зур түгел. Тышкы транспорт, җирлекнең район һәм республика үзәкләре һәм күрше-тирә муниципаль берәмлекләр белән багланышы җәһәтеннән, зур әһәмияткә ия.

Җирлекнең торак пунктлары белән янәшәдә генә федераль әһәмияткә ия булган “Бөгелмә-Уральск” автомобиль юлы уза.

Акбаш авыл җирлеге территориясендә юл челтәрен үстерү җәһәтеннән төп чаралар Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең 2020 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш планында каралган.

Тышкы транспортны үстерү өлешендә Программа чаралары булып торалар:

1. Акбаш авыл җирлеген территориаль планлаштырганда җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын норма хәленә китерүне исәпкә алу (барлык чорга).

2. Муниципаль берәмлек чикләрендә федераль һәм региональ әһәмияткә ия булган автомобиль юллары үстерү өчен җир кишәрлекләре бүлеп бирүгә теләктәшлек итү (барлык чорга).

3. Федераль һәм региональ әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының тармакларын һәм саклаулы зоналарын файдалану режимын саклауны тәэмин итү (барлык чорга).

Җәмәгать транспорты.

Транспорт – җирлек инфраструктурасының йөк ташу һәм пассажирлар йөртү буенча икътисадның барлык тармакларының һәм халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерә, җитештерүчеләр һәм кулланучылар арасында продукциянең төрле төрләрен йөртә, халыкка һәркем куллана алырлык транспорт хезмәте күрсәтә торган мөһим состав өлеше.

Транспортның тотрыклы һәм нәтиҗәле эшләве халыкның йөк ташуга булган ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү һәм җирлектәге барлык предприятиеләрнең уңышлы эшләве өчен кирәкле шарт булып тора. Җирлектә пассажир транспортының бердәнбер һәм төп төре булып такси һәм шәхси машиналар тора. Җирлек территориясе аша түбәндәге автотранспорт маршруты уза: Бөгелмә – Северное. Акбаш авыл җирлеге территориясендә автотранспорт предприятиеләре юк. Авыл җирлеге торак пунктлары белән район үзәге арасында хәзерге вакытта автобус транспорты юк. Бөгелмә шәһәре һәм Северное авылы арасында регуляр автобус элемтәсе бар. Җирлектә хәрәкәтләрнең күпчелеге шәхси автотранспортка һәм җәяүле йөрүләргә туры килә.

4. Урам – юл челтәре

Урам-юл челтәре торак пунктлардагы транспорт, инженерлык һәм социаль инфраструктурасын тәшкил итә торган төп элемент булып тора. Җирлекнең комплекслы үсешендә юл челтәренең һәм инфраструктур объектларның үсеше аеруча социаль әһәмияткә ия булып тора. Акбаш авыл җирлегендә урам-юл челтәренең озынлыгы 9,41 км тәшкил итә. Җирлектә автомобиль юлларының күпчелек өлешенә вак таш түшәлгән.

Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге урам-юл челтәре сыйфатламасы 1нче Таблицада бирелә.

Таблица 1

| № п/п | Автомобиль юлы исеме | Озынлык, км | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Шул исәптән | | | |
| | | | ц/б | а/б | Вак ташлы | грунт |
| 1 | ул. Шоссейная | 2,2 | | 1,8 | 0,2 | 0,2 |
| 2 | ул. Школьная | 0,31 | | 0,05 | 0,26 | |
| 3 | ул. Фестивальная | 0,2 | | 0,2 | | |
| 4 | ул. 50 лет Октября | 0,3 | | | 0,3 | |
| 5 | ул. Железнодорожная | 0,4 | | | | 0,4 |
| 6 | ул. Советская | 1,5 | | | 1,5 | |
| 7 | ул. Заречная | 1,5 | | | 0,1 | 1,4 |
| 8 | ул. Ключевская | 1,5 | | | 0,1 | 1,4 |
| 9 | ул. Даньшина | 1,5 | | | | 1,5 |
| | **Барлыгы** | **9,41** | **0** | **2,05** | **2,46** | **4,9** |

## 5. Транспорт комплексы үсеше приоритетлары

2029 елга кадәр муниципаль берәмлекнең транспорт комплексы үсешендә төп приоритетлар булырга тиеш:

Булган урам-юл челтәре капламнарын ремонтлау һәм реконструкцияләү.

Акбаш авыл җирлеге территориясендә транспортны үстерү төрле дәрәҗә хакимиятләрнең: федераль, региональ, муниципаль властьларның уртак тырышлыгына йөз тотып, комплекслы якын килүгә нигезләп алып барылырга тиеш. Авыл җирлегендә транспорт системасын үстерүне планлаштырганда, район һәм төбәк транспорт системасының перспективадагы үсеше исәпкә алынырга тиеш. Авыл җирлегендәге транспорт системасы регионның транспорт системасы элементы булып тора, шуңа күрә дә территориядә транспорт инфраструктурасын оптимальләштерүгә бәйле барлык бурычларны да чишү бары тик җирлекнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре кысаларында гына хәл ителә алмый. Программа тарафыннан транспорт инфраструктурасын үстерүгә кагылышлы тәкъдимнәр барлык дәрәҗәдәге бюджетлар катнашында гамәлгә ашырылуны күздә тота. Җирлекнең җирле үзидарә органнарының бурычы булып дәүләт власте органнары белән җирле үзидарә арасында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү чараларын оештыру, транспорт инфраструктурасын үстерү буенча инициативалы тәкъдимнәр әзерләү тора. Транспорт инфраструктурасы үсешенең федераль дәрәҗәдәге төп юнәлешләре РФ Хөкүмәтенең 2008 елның 22 ноябрендә биргән №1734-р күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясе транспорт стратегиясе тарафыннан билгеләнгән.

Транспорт стратегиясенә ярашлы рәвештә, транспорт системасы үстерүнең стратегик максаты – икътисадның һәм җәмгыятьнең социаль юнәлешле инновацион үсеш ихтыяҗларын һәм көндәшлеккә сәләтле булган яхшы сыйфатлы транспорт хезмәтләренә булган ихтыяҗларны канәгатьләндерү.

Көндәшлеккә сәләтле булган нәтиҗәле транспорт системасын булдыру өчен төп 3 өлеш кирәк:

Көндәшлеккә сәләтле югары сыйфатлы транспорт хезмәте күрсәтү;

Көндәшлеккә сәләтле югары сыйфатлы транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итәрлек дәрәҗәдә югары җитештерүчән куркынычсыз транспорт инфраструктурасы һәм транспорт чаралары;

Транспорт хезмәтләренә тәкъдимнәрне сораудан күбрәк булырлык дәрәҗәдә арттыру өчен шартлар булдыру (шулай түгел икән, көндәшлек мохите булмаячак)

## 6. Урам-юл челтәрен оптимальләштерү

Җирлектә транспорт комплексын үстерүнең югарыда билгеләнгән приоритетларына туры китереп, Программа тарафыннан урам-юл челтәрен оптимальләштерүнең түбәндәге чаралары каралган.

Программа тарафыннан магистраль урам-юллар челтәрен нормативларга туры китереп формалаштыру буенча тәкъдимнәр бирелә. Авыл торак пункты һәм авыл җирлеге чикләрендә урам челтәре параметрларының төп исәпләү саннары “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” СП 42.13330.2011  кагыйдәләренә туры китереп кабул ителә.

Яңа торак төзелеше районнарында урамнарны һәм юлларны проектлаганда, урамнарның проектлардагы кызыл сызык киңлекләрен сакларга кирәк, бу алга таба җир участокларын алу, урамнарны киңәйтү максатыннан капиталь төзелеш объектларын сүтү кебек кыйммәтле чараларны булдырмый калырга ярдәм итәчәк. Проектлана торган урамнар, норматив тайпылыш таләпләре үтәлсен өчен, шул рәвешле, рельефка урнашырга тиеш. Катлаулы геоморфологик факторлар булганда, төп урамнарны проектлауга һәм төзүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә.

## 7. Транспортның туктап тору һәм озак вакытка куеп саклау урыннарын оештыру

Җирлек территориясендә автотранспортны саклау, нигездә, предприятие участокларында һәм җирлектә яшәүчеләрнең йортлары тирәсендә, зур булмаган гараж кооперативларында башкарыла. Киләчәктә автомобильләрне җәмәгать кулланыы биналары тирәсендә, халыкта автомобильләр саны артуны күздә тотып, оештыруны карарга кирәк. Халыкның җиңел автомобильләрен даими һәм вакытлыча хуҗалык яны участокларында куеп саклау тору күздә тотыла.

Әлеге бүлек буенча үтәү зарур булган чаралар:

1. Кирәкле сандагы транспорт кую урыннарын, җәмәгать биналарының сыйдырышлылыгын исәпкә алып, аларны төзү өчен билгеләнгән участокларда урнаштыруның, төзекләндерүнең административ чараларын тәэмин итү (барлык чорга);

2. Хезмәт күрсәтү объектлары янында аввтостоянкалар төзү (бөтен вакыт);

3. Күпләп җыела торган урыннарда җәмәгать машиналарын кую урыннарын оештыру (беренче чиратта – исәпләү срогы).

## 8. Җәяүлеләр урамнарын һәм велосипед юллары системасын булдыру: мөмкинлекләре чикле затлар өчен каршылыксыз мохитне тәэмин итү

Экологик чиста мохитне саклау, корреспонденция өчен кыска араларда, торак пунктлары территориясендә Программа тарафыннан җәяүлеләр урамнары системасы да карала. Җирлек программасы аз хәрәкәтләнүче халык төркемнәре өчен каршылыксыз мохит тудыруны күздә тота. Бу максат белән җәмәгать биналарын проектлаганда, тиешле нормалы авышлыктагы пандуслар төзүгә аерым таләпләр куелырга, тротуарлар капламын камилләштерү һәм каршылыксыз мохит булдыру өчен билгеләнгән барлык таләпләр үтәлергә тиеш.

Бу бүлектә каралган чаралар:

1. Җәяүлеләр хәрәкәтенә өстенлек бирелә торган урамнар системасын формалаштыру (исәпләү срогы – перспективада);

2. Төзүчеләр тарафыннан каршылыксыз мохит булдыру таләпләрен административ чаралар ярдәмендә үтәүне тәэмин итү (барлык чорга).

Экологик чиста мохитне саклау өчен, торак пунктлар территориясендә җәяүлеләр урамнары системасы карала. Авыл җирлеге программасы ярдәмендә халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен киртәләрсез мохит булдыру күздә тотыла. Бу максаттан җәмәгать биналарын проектлаганда норматив тайпылышлар булган пандусларны, тротуарларның өслеген камилләштерү һәм каршылыксыз мохит булдыруга кертелгән барлык кирәкле таләпләрне үтәү буенча таләпләр куелырга тиеш.

Программа чаралары

Таблица 2

| Чараның атамасы | Объектның урнашкан урыны | Гамәлгә ашыру сроклары |
| --- | --- | --- |
| Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының техник документларындагы мәгълүматларны | п. ж/д ст. Акбаш, Андреевка, Кирилловка | 2019-2029 еллар |

| | | |
|---|---|---|
| актуальләштерү, тармак полосоларын билгеләү | авыллары | |

Таблица 2 дәвамы

| Чараның атамасы | Объектның урнашкан урыны | Гамәлгә ашыру сроклары |
|---|---|---|
| Җирлектәге барлык автомобиль юлларындагы һәм урамнардагы инженерлык корылмаларының техник торышына бәя биреп, инвентарьлаштыру уздыру | п. ж/д ст. Акбаш, Андреевка, Кирилловка авыллары | 2019-2029 еллар |
| Җирле әһәмияттәге расланган автоюллар исемлегенә, юл капламының үзгәрүен исәпкә алып, үзгәрешләр кертү | п. ж/д ст. Акбаш, Андреевка, Кирилловка авыллары | 2019-2029 еллар |
| Территорияләрне планлаштыру документлары белән берлектә башкарыла торган юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча чаралар комплексын эшләү, гамәлгә ашыру | п. ж/д ст. Акбаш, Андреевка, Кирилловка авыллары | 2019-2029 еллар |
| Торак пунктлардагы урамнарда каты капламнарны реконструкцияләү, ремонтлау, төзекләндерү | п. ж/д ст. Акбаш, Андреевка, Кирилловка авыллары | 2019-2029 еллар |
| Торак һәм сәнәгать төзелеше өчен яңа территорияләрне үзләштергән вакытта юл һәм тротуарларны комплекслы төзү | п. ж/д ст. Акбаш, Андреевка, Кирилловка авыллары | 2019-2029 еллар |
| Җәмәгать транспорты өчен туктау мәйданчыкларын һәм павильоннарын урнаштыру, җиһазлау | п. ж/д ст. Акбаш, Андреевка, Кирилловка авыллары | 2019-2029 еллар |